ГОСУДАРСТВЕННЫЙ
КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

10.02.2022 № 24-од

г. Казань

«Гаилә архивын тапшыр»
ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы турында

Гаилә тарихы аша ил һәм туган як тарихын өйрәнүгә нигезләнеп, яшь буында ватанпәрвәрлек тәрбияләүгә ярдәм итү, туган як тарихы белән кызыксынуны саклап калу һәм арттыру, гаилә кыйммәтләрен һәм буыннар арасында элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү, архив материаллары белән эшләүгә җәлеп итү, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын уку, Татарстан Республикасы Архив фондын кыйммәтле тарихи чыганаклар белән баету максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелгән «Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган республика конкурсы (алга таба – Конкурс) турында нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең оештыру-методика бүлегенә җаваплы башкаручыларны билгеләргә, Конкурсны расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә оештырырга һәм үткәрергә.

3. Финанс-икътисад бүлегенә Конкурста җиңүчеләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан чаралар исәбеннән акчалата түләүләр башкарырга.

4. «2019 – 2020 елларга «Гаилә архивын тапшыр» конкурсы турында» 2019 елның 17 сентябрендәге 178-од номерлы боерыкны үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны рәис урынбасары И.Г. Шәриповка йөкләргә.

Рәис Г. З.Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының
10.02.2022 № 24-од
боерыгы белән
расланды

«Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган республика конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү һәм оештыру тәртибен, шартларын, конкурс эшләрен бәяләү критерийларын билгели.

1.2. Конкурсның максатлары: гаилә тарихы аша ил һәм туган як тарихын өйрәнүгә нигезләнеп, яшь буында ватанпәрвәрлек тәрбияләү; туган як тарихы белән кызыксынуны саклап калу һәм арттыру; гаилә кыйммәтләрен һәм буыннар арасында элемтәләрне ныгытуга ярдәм итү; архив материаллары белән эшләүгә, тарихи һәм туган якны өйрәнү әдәбиятын укуга җәлеп итү; Татарстан Республикасы Архив фондын кыйммәтле тарихи чыганаклар белән баету.

1.3. Конкурсны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты), Конкурсны оештыручы - «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – ТР Дәүләт архивы).

1.4. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 июнендәге 395 номерлы карары белән расланган «2016 – 2024 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасында каралган максатчан чаралар хисабына гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурста катнашучылар

2.1. Конкурста катнашу бушлай, ирекле рәвештә башкарыла.

2.2. Конкурста гаилә архивлары хуҗалары катнаша.

Гаилә архивы хуҗасы дигәндә гаиләдәге вакыйгаларны чагылдыра торган документларга ия зат күз алдында тотыла. Әгәр конкурска гаиләнең башка әгъзалары документлары тапшырылса, гариза бирүче зат шулай ук әлеге Нигезләмәгә 2 нче, 3 нче кушымталарда каралган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык һәм әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган Конкурста гаиләнең башка балигъ әгъзалары исеменнән катнашуга ризалык тапшыра.

2.3. Конкурска Татарстан Республикасының барлыкка килүе, үсеше тарихын чагылдыра торган гаилә архивлары кабул ителә.

## III. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Конкурс турыдан-туры очрашып үткәрелә. Конкурста катнашучыларның эшләре 2 этапта карала:

1 этап – муниципаль, Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре) тарафыннан үткәрелә;

2 этап – республика.

3.2. Конкурс этапларын үткәрү даталары һәм конкурс документларын тапшыру срогы, конкурста катнашу өчен сайлап алу, гаризалар кабул итү шартлары һәм критерийлары, конкурс эшләрен кабул итә башлаганчы ун календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (http://arhiv.tatarstan.ru) (алга таба - ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайты) урнаштырыла.

3.3. Конкурста муниципаль этапта катнашу өчен гариза, әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән ризалыклар, гаилә архивы документларының электрон күчермәләре Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе) адресына электрон рәвештә һәм/яисә кулдан-кулга, почта аша гариза тапшырыла.

3.4. Конкурста катнашуга тиешле вакыт эчендә тапшырылган, эчтәлеге һәм төзелеше әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килә торган конкурс документлары алына.

3.5. Муниципаль этап нәтиҗәләре буенча конкурсның республика этабына Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан бер гаилә архивы, Татарстан Республикасы шәһәр округларыннан дүрт гаилә архивы, Казан шәһәреннән җиде гаилә архивы җибәрелә.

3.6. Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре) электрон рәвештә peredai-family-arhiv2021@yandex.ru электрон почта адресына һәм / яисә кулдан-кулга, ТР Дәүләт архивы адресына почта аша: Столбище авылы, Совет урамы, 277 нче йорт, «Гаилә архивын тапшыр» тамгасын куеп, муниципаль этапта җиңүчеләрнең түбәндәгеләрдән гыйбарәт документлар пакетын тапшыралар: конкурста катнашу өчен гариза (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта), шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга рөхсәт (әлеге Нигезләмәгә 2 нче, 3 нче кушымталар), Конкурста гаиләнең башка балигъ әгъзалары исеменнән катнашуга ризалык (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта), шәхси бәяләү кәгазьләре (әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымта), конкурсның муниципаль этабы конкурс комиссиясе беркетмәсе (әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымта), шулай ук гаилә архивы документларының электрон күчермәләре/яки төп нөсхәләре (исемлек буенча).

## IV. Конкурсны оештыру комитеты

4.1. Конкурс үткәрү һәм гаилә архивларын сайлап алу өчен Татарстан Республикасының һәр муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитетының архив бүлеге (идарәсе) вәкилләреннән, музей хезмәткәрләреннән, фәнни белгечләрдән комиссия функцияләре белән (конкурс эшләрен бәяләү, муниципаль дәрәҗәдә (шәһәр дәрәҗәсендә) катнашучылар рейтингын төзү һәм аларны сайлап алу) район (шәһәр) оештыру комитетлары төзелә.

4.2. Конкурсның республика этабын оештыру, үткәрү һәм йомгак ясау өчен ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, ТР Дәүләт архивы вәкилләреннән оештыру комитеты рәисе, рәисе урынбасары һәм әгъзалары составында республика оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзелә.

4.3. Оештыру комитеты функцияләре:

конкурсның оештыру эшләре буенча әзерлеген һәм үткәрелүен тәэмин итү;

муниципаль районнар (шәһәр округлары) башкарма комитетларының архив бүлекләре (идарәләре) тарафыннан сайлап алынган конкурс гаризаларын җыю;

массакүләм мәгълүмат чараларында, ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, ТР Дәүләт архивы сайтларында конкурс барышы турында хәбәр итү;

комиссия беркетмәсе нигезендә җиңүчеләр исемлеген төзү.

4.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.1 һәм 4.2 пунктларында күрсәтелгән оештыру комитетларының эше аларның утырышларында гамәлгә ашырыла. Әгәр аларда оештыру комитетлары әгъзаларының гомуми саныннан күпчелеге катнашса, утырыш хокукка ия дип санала.

## V. Конкурс комиссиясе

5.1. Конкурска бирелгән иң яхшы гаилә архивларына бәя бирү һәм җиңүчеләрне билгеләү максатыннан Конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

5.2. Комиссиянең персональ составы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, ТР Дәүләт архивы, республика башкарма хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмалары вәкилләреннән, фәнни бергәлек вәкилләреннән Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм әгъзалары составында кимендә 7 кешедән гыйбарәт булып, ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.3. Комиссия эше белән рәис җитәкчелек итә. Ул булмаган очракта, аның бурычлары аның урынбасарына йөкләнә. Конкурс нәтиҗәләрендә шәхси мәнфәгатьләре булган затлар Комиссия әгъзалары була алмый.

5.4. Комиссия эше аның утырышында башкарыла. Әгәр утырышта аның әгъзаларның гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, утырыш хокуклы дип санала.

5.5. Конкурска бирелгән гаилә архивларын бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

бәяләү критерийларына нигезләнеп, бирелгән материалларны бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлек.

5.6. Комиссия әгъзалары һәр критерий буенча баллар куя, һәм алар кушыла. Һәр критерий буенча баллар саны 10 баллы шкала буенча билгеләнә (0 дан алып 10 га кадәр).

Баллар «Индивидуаль бәяләү кәгазьләре»нә кертелә, Комиссия әгъзасы имзасы белән таныклана һәм Комиссия рәисенә тапшырыла (әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымта).

5.7. Комиссия әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 7 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар буенча куелган баллларны кушканнан соң, катнашучыларның йомгаклау рейтингы төзелә, ул Комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

5.8. Конкурсның берничә катнашучысы бертигез баллар санын җыйса, рәис тавышы хәлиткеч була.

## VI. Гаилә архивларының эчтәлегенә карата таләпләр

6.1. Конкурста катнашучылар сайлап алу үткәрү өчен түбәндәгеләрне тапшыра:

төп чыганакта үз гаилә архивының фотодокументлары: позитив, негатив, слайдлар, кәгазь позитив (фотография), фотоальбом, пыялада негатив;

төп чыганакта үз гаилә архивының видеодокументлары (видеокассеталар, видеодисклар, флэш туплагыч);

төп чыганакта үз гаилә архивының фонодокументлары (магнит тасма, магнит кассета, оптик диск, флэш туплагыч)

үзенең гаилә архивыннан шәхси документлар;

тәкъдим ителгән фото -, фоно -, видеодокументларга, үз документларына аннотацияләр;

гаиләнең кыскача тарихы, гаилә әгъзаларының, шул исәптән хезмәт ветераннарының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның иҗтимагый һәм һөнәри эшчәнлеге турында мәгълүматлар.

7.2. Эшләр татар һәм (яки) рус телләрендә тапшырыла.

## VII. Бәяләү критерийлары

Бәяләү критерийлары:

конкурсның максатларына туры килү (0 алып 10 баллга кадәр);

архив документларының тулылыгы һәм мәгълүмати байлыгы (0 алып 10 баллга кадәр);

гаилә документларында Татарстан оешуның, аның үсешенең төп чорлары чагылу дәрәҗәсе (0 алып 10 баллга кадәр);

архив документларының физик торышы (0 алып 10 баллга кадәр);

конкурска тәкъдим ителгән документларның төрлелеге (шул исәптән фото, видео, фонодокументлар, үз документлары) (0 алып 10 баллга кадәр).

## VIII. Җиңүчеләрне билгеләү, нәтиҗәләр чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе

8.1. Документлар пакеты тапшырылганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия утырышы үткәрелә.

8.2. Комиссия утырышында Конкурста җиңүчеләр исемлеге катнашучыларның йомгак рейтингы нигезендә төзелә.

8.3. Конкурста җиңүчеләр дип рейтингта беренче өч урынны алган катнашучылар танылa.

8.4. Конкурста җиңүчеләр исемлеге ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән, Комиссия утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмәгә кул куелган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча раслана.

8.5. Конкурста җиңүчеләр исемлекләре боерыкка кул куелган көннән алып 3 эш көне эчендә ТР Архив эше буенча дәүләт архивының, ТР Дәүләт архивының рәсми сайтларына урнаштырыла.

8.6. Конкурста җиңүчеләр түбәндәгечә бүләкләнә:

конкурс дипломнары һәм түбәндәге күләмдәге акчалата премияләр белән:

50 000 (илле) мең сум – I урын өчен

30 000 (утыз) мең сум – II урын өчен

20 000 (егерме) мең сум – III урын өчен.

8.7. Оештыру комитеты, Конкурс нәтиҗәләренә нигезләнеп, гаилә кыйммәтләрен, гаилә вакыйгаларын, бәйрәмнәрен, гаиләнең өстенлекле кыйммәтләрен, буыннар арасындагы элемтәне чагылдыручы документлар булган өчен «Гаилә традицияләре» номинациясе буенча юаткыч бүләк кертә ала.

8.8. Конкурста җиңүчегә түләнергә тиешле сумма Татарстан Республикасы бюджетына салым, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр күләменә киметелә.

8.9. Конкурста катнашучылар тапшырыла торган документларның дөреслеген, шулай ук тапшырыла торган материалларны төзегәндә өченче затларның авторлык һәм башка хокуклары бозылмавын гарантияли.

Әлеге шарт бозылган очракта, конкурста җиңүчеләргә бүлеп бирелгән акчалар Татарстан Республикасы бюджетына законнарда билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

## IX. Өстәмә мәгълүмат

9.1. Конкурста җиңгән гаилә архивлары документларының төп нөсхәләре ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына саклауга кабул ителә һәм Татарстан Республикасы Архив фонды составына кертелергә тиеш. Документлар архивка шартнамә төзеп алына.

9.2. Тапшырылган документларга авторлык хокуклары конкурста катнашучыларда кала.

9.3. Конкурсны оештыручы архив чараларын таныту максатларында, мәгълүмат һәм презентация материалларын ясау өчен конкурс эшләрен, шул исәптән

конкурска гаризаларга беркетеп җибәрелгән фотоларны, видеороликларны һәм башка документларны авторлык хокукларын саклап куллану хокукын үзендә калдыра.

9.4. Җиңүчеләр исемлегенә кермәгән конкурста катнашучыларның барысына да конкурста катнашучылар сертификатлары бирелә, алар җиңүчеләр исемлеге урнаштырылганнан соң 10 эш көне эчендә катнашучының электрон адресына электрон рәвештә җибәрелә.

«Гаилә архивын тапшыр»
ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы
турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

«Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган
республика конкурсында катнашу өчен
гариза

| | |
|---|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) | |
| Катнашучының, индекс күрсәтелеп, теркәлү (чынбарлыкта яшәү) адресы | |
| Катнашучының элемтә өчен телефоннары | |
| Катнашучының E-mail адресы | |

«Гаилә архивын тапшыр»
ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны
эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга
рөхсәт

Мин ____________________________________________________________,
*Конкурста катнашучының ФИАи тулысынча (соңгысы – булган очракта)*
_________________________________________________________________ укыйм,
элемтә өчен телефоным: _____________________________________________
«Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган республика конкурсы үткәрелү кысаларында «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә (алга таба – Оператор), «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында каралганча, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә үземнең шәхси мәгълүматларымны автоматлаштыру чараларын кулланып эшкәртүгә, Оператор сайтларында (http://arhiv.tatarstan.ru) казанышларым турында мәгълүмат урнаштыруга һәм Конкурс җиңүчеләре турында мәгълүмат урнаштыруга ризалык бирәм.

Моның белән Операторга шәхси мәгълүматларның түбәндә санап кителгән категорияләрен карый торган шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм:

1. ФИАи
2. Элемтә өчен телефон
3. Мәгариф оешмасы
4. Социаль статус

Шәхси мәгълүматларымны бары тик түбәндәге максатларда файдалануга ризалык бирәм:

- эшне төзү һәм эшкәртү;
- тапшырылган конкурс материалларын карау;
- статистика алып бару;
- Операторның рәсми сайтында конкурс нәтиҗәләрен чыгару;
- югарыда күрсәтелгән максатлар белән бәйле башка гамәлләр.

Минем сурәтләрне «Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган республика конкурсы үткәрелү кысаларында басма матбугатларда, интернет челтәрендә, радио- һәм телевизион эфирда урнаштырыла торган мәгълүмати һәм башка материалларда файдалануга ризалык бирәм.

Сурәтләрем минем намусыма, вөҗданыма һәм эшлекле абруема тап төшерә торган ысуллар белән файдалана алмый.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалык бирелгән вакытыннан алып вакыты чикләнмичә гамәлдә була һәм минем тарафтан, Операторга Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә гади язма рәвештәге гариза тапшырылып, кире алынырга мөмкин.

"___" _________, 20___ ел _____________________ _________________

(конкурста катнашучы имзасы) (фамилия, инициаллар)

«Гаилә архивын тапшыр»
ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы
турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Таратырга шәхси мәгълүматлар субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин,_______________________________________________________________________,
шәхси мәгълүматлар субъектының Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта) тулысынча

элемтә өчен телефон: ____________________, электрон почта адресы ____________________,

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның $10^1$ статьясын нигез итеп алып, «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә (ИНН 1655369841, ОГРН 1161690140809, урнашу урыны: Столбище авылы, Совет урамы, 277) (алга таба – Оператор) «Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү кысаларында «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенең рәсми сайтында минем хакта мәгълүмат урнаштыру максатларында минем шәхси мәгълүматларымны түбәндәге тәртиптә таратырга ризалык бирүем турында белдерәм:

| Шәхси м ә г | Шәхси мәгълүматлар исемлеге | Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Чикләнмәгән затлар даирәсенә таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Шартлар һәм тыюлар | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилия | | | | |
| | Исем | | | | |
| | Атасының исеме | | | | |
| | Мәгариф оешмасы | | | | |
| | Социаль статус | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Йөзнең төсле цифрлы фотография сурәте | | | | |

Шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларыннан чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алачак һәм алар белән башка гамәлләр башкарылачак Операторның мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

| Мәгълүмат ресурсы | Шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр |
|---|---|
| h | Чикләнмәгән затлар даирәсенә бирү |

Әлеге ризалыкны үз ихтыярым белән бирәм һәм «__» ________, 20__ел алып «__» _________, 20__ ел кадәр гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатуны таләп итү хокукы үземдә кала. Таләп куелган очракта, Оператор кичекмәстән минем шәхси мәгълүматларымны таратуны туктатырга, шулай ук шәхси мәгълүматлар тапшырылган өченче затлар исемлеген хәбәр итәргә тиеш.

| дата | имза | фамилия, инициаллар |
|---|---|---|

«Гаилә архивын тапшыр»
ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы
турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

Конкурста гаиләнең башка балигъ әгъзалары исеменнән катнашуга ризалык

Мин ____________________________________(Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта) тулысынча) гаиләнең башка балигъ әгъзаларыннан «Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган республика конкурсында (алга таба – Конкурс) катнашуга ризалык(лар) алдым.

Конкурста катнашуга һәм шуңа бәйле рәвештә шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә түбәндәгеләр ризалык бирде:

___________________________________________________________________________

(*Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта), имза*)

___________________________________________________________________________

(*Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта), имза*)

Гаилә архивының хуҗасы ________________________________________________

(*Ф.И.Аи. (соңгысы – булган очракта), имза*)

________________________

(дата)

«Гаилә архивын тапшыр»
ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы
турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

## Индивидуаль бәяләү кәгазьләре

| Гариза бирүченең ФИАи, конкурс эшенең исеме һәм эшне тәкъдим итү форматы | |
|---|---|
| Критерийлар | 0 алып 10 баллга кадәр |
| конкурсның максатларына туры килү | |
| архив документларының тулылыгы һәм мәгълүмат ягыннан байлыгы | |
| гаилә документларында Татарстан оешуның, аның үсешенең төп чорлары чагылу дәрәҗәсе | |
| архив документларының физик торышы | |
| конкурска тәкъдим ителгән документларның төрлелеге (шул исәптән фото, видео, фонодокументлар, шәхси документлар) | |
| БАРЛЫГЫ | |

«___» ___________, 20____ ел                _________________________ /_________________________

Төзелү датасы                Комиссия әгъзасы имзасы        Бәяләмә имзасын аңлатып язу

«Гаилә архивын тапшыр»
ел саен үткәрелә торган
республика конкурсы
турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта

«Гаилә архивын тапшыр» ел саен үткәрелә торган республика конкурсының
муниципаль этабы конкурс комиссиясе утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ

Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районы (шәһәр округы)
башкарма комитетының Архив бүлеге (идарәсе)

Архив бүлегенең почта адресы (идарәсе), e-mail____________________________
(индекс, муниципаль район,

_____________________________________________________________________
шәһәр, район, урам, йорт)

Муниципаль архив җитәкчесенең ФИАи (тулысынча), телефон

_____________________________________________________________________

Конкурсның муниципаль этабы комиссиясе рәисе ФИАи (тулысынча)

_____________________________________________________________________

Утырыш көне ____________________________________________________________

Конкурсның республика этабына гаилә архивы документларын тапшырырга:

_____________________________________________________
(Катнашучының исем-фамилиясе)

Комиссия әгъзаларының имзалары:
(имза) (ФИАи, вазыйфа)_____________________________

(имза) (ФИАи. вазыйфа) _____________________________

(имза) (ФИАи. вазыйфа) _____________________________

Беркетмә расланды_____________________________________
(муниципаль этап комиссиясе рәисе имзасы)